**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**ТЮЛЯЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Фатыха Хусни ул., д. 10, с. Тюлячи 422080
тел. (факс): (84360) 2-02-12
E-mail: Tlc.Tul@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Фатых Хөсни ур., 10 нче йорт, Теләче авылы 422080
тел. (факс): (84360) 2-02-12
E-mail: Tlc.Tul@tatar.ru

ОКПО 48674966  ОГРН 1021607156691  ИНН/КПП 1619000368/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 9** **14 октября 2022г.**

**Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең Екатериновка авылында 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Теләче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең Екатериновка авылында 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 26 октябренә 14:30 сәгатькә билгеләргә, түбәндәге адрес буенча: Екатериновка ав., Советская ур., 22 й. (№15 торак йорты янында).
2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан тәэмин ителә.
3. Торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүлүне сайлау тәртибе.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«Сез Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегенең Екатериновка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 2023 елда 600,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм чараларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне чишү өчен юнәлтүгә ризамы:

- «Святой ключ» чишмәсен төзекләндерү;
- Үлән чаптыру, чүп-чар җыю һәм чыгару;
- Юлны ремонтлау?»,

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Теләче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Теләче муниципаль районының рәсми сайтында (http://tulachi.tatarstan.ru), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Н.Н. Хаҗипов